ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
КАРАР

№ 5 05.11.2020 ел

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәлесе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Татар Сөнчәле авылы, Тукай урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Татар Сөнчәле авыл клубы бинасы янында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителде.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Мюд авыл җирлеге Татар Сөнчәлесе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Татар Сөнчәлесе авылы торак пунктында юлларга вак таш сатып алу
- Татар Сөнчәлесе авылы торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т. В. Зюзина

СОВЕТ МЮДОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ